**Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы**
**Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №171-43 16 июнь 2020 ел

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советына депутатлар сайлауларын билгеләү турында

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»Федераль законның 23 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Уставының 13 статьясы нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советы **карар итте:**

1. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советына депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны, аны кабул иткән көннән биш көннән дә соңга калмыйча, район «Маяк» газетасында бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http:// aznakyevo.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Азнакай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Рәис М. З. Шәйдуллин